**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеген Күлле-Киме торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"15" ноябрь 2022 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №109 карары нигезендә, 2022 елның 15 ноябрендә «Сез 2023 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны кардан чистарту, үләннәрне чабу
- баннер ясату
- уен мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру
- янгын гидрантларын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау
- урам юлының асфальт өслеген ремонтлау
- урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу
- коеларга өслек сатып алу һәм урнаштыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 213 (ике йөз унөч) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 124 (йөз егерме дүрт) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 124 (йөз егерме дүрт) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучылар 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Сез 2023 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк

гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: "Күлле-Киме авылында җирлек территориясен чистарту һәм төзекләндерү

- урамнарны кардан чистарту, үләннәрне чабу
- баннер ясату
- уен мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру
- янгын гидрантларын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау
- урам юлының асфальт өслеген ремонтлау
- урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу
- коеларга өслек сатып алу һәм урнаштыру

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гәрәев Х.Х.